| | |
|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

**«Каравон» рус халык бәйрәмен уздыру турында**

«Татарстан Республикасының бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталары турында» 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тәкъдимнәрен исәпкә алып, 2020 елның 23 маен «Каравон» рус халык бәйрәмен уздыру көне дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы территориясендә яңа короновирус инфекциясе таралу куркынычы белән бәйле кертелгән чикләү чараларын үтәү тәэмин ителә торган формада «Каравон» рус халык бәйрәменә багышланган чараларны уздыруны оештырырга.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән бергәләп «Каравон» рус халык бәйрәменә, шул исәптән аның тарихына һәм традицияләренә багышланган чараларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 19 май
№ ПУ-296